**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 14 маендагы 10-38 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасы депутаты таныклыгы һәм күкрәк билгесе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законның 40 статьясы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 82 статьясы нигезендә Казан шәһәре Думасы карар бирде:

1. Казан шәһәре Думасы депутаты таныклыгы һәм күкрәк билгесе турындагы Нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 14 маендагы
10-38 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Думасы депутаты таныклыгы**
**һәм күкрәк билгесе турында**
**Нигезләмә**

1. Казан шәһәре Думасы депутаты таныклыгы (алга таба – таныклык) Казан шәһәре Думасы депутаты (алга таба – депутат) вәкаләтләрен раслый торган төп документ булып тора

2. Таныклык әлеге Нигезләмәгә 1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә депутат таныклыгы үрнәге һәм тасвирламасы нигезендә типография ысулы белән әзерләнә.

3. Депутатның күкрәк билгесе (алга таба – күкрәк билгесе) депутат таныклыгы булганда депутатның аермалы билгесе булып тора. Күкрәк билгесе киемгә беркетелә һәм күкрәкнең сул ягына тагыла.

4. Күкрәк билгесе әлеге Нигезләмәгә 3 номерлы кушымта нигезендә депутатның күкрәк билгесе тасвирламасы нигезендә әзерләнә.

5. Депутатка таныклык һәм күкрәк билгесе Казан шәһәре Мэры сайланганнан соң бер ай эчендә бирелә.

6. Депутатның таныклыгы Казан шәһәре Мэры тарафыннан имзалана һәм Казан шәһәре Думасы мөһере белән таныклана.

7. Депутатка таныклыкны һәм күкрәк билгесен рәсмиләштерүне Казан шәһәре Думасы аппараты гамәлгә ашыра.

8. Депутатларга таныклыклар һәм күкрәк билгеләре тапшыру Казан шәһәре Мэры тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Таныклык һәм күкрәк билгесе Казан шәһәре Думасы депутатлары таныклыкларын һәм күкрәк билгеләрен бирүне исәпкә алу журналында (алга таба – теркәү журналы) мәҗбүри теркәлергә тиеш.

10. Теркәү журналы әлеге Нигезләмәгә 4 номерлы кушымта нигезендәге форма буенча тиешле чакырылыш Казан шәһәре Думасы вәкаләтләре чорына рәсмиләштерелә.

Теркәлү журналын алып бару һәм саклау Казан шәһәре Думасы аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

11. Депутат таныклыктан һәм күкрәк билгесеннән агымдагы чакырылыш депутат вәкаләтләре чоры дәвамында файдалана.

12. Депутат таныклыкның һәм күкрәк билгесенең саклanышын тәэмин итәргә тиеш. Таныклык һәм күкрәк билгесе башка затка тапшырылырга тиеш түгел.

13. Таныклык һәм (яисә) күкрәк билгесе югалган (зыян күргән) яисә бозылган очракта, депутат Казан шәһәре Мэры исеменә яңа таныклык һәм (яисә) күкрәк билгесе бирү турында язма гариза бирә, анда югалту (зыян күрү) яисә бозылу сәбәпләре күрсәтелә. Депутат таныклыгын югалткан очракта, аңа башка номер белән таныклык рәсмиләштерелә һәм тапшырыла. Депутат таныклыгы һәм (яисә) күкрәк билгесе бозылып, элек бирелгән таныклык һәм (яисә) күкрәк билгесе кире кайтарылган очракта, алар шул ук номер белән яңаларына алмаштырыла.

14. Таныклыкның югалу факты турындагы мәгълүмат, таныклык номерын, депутатның фамилиясен, исемен, атасының исемен күрсәтеп, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» (ww.docskzn.ru) челтәре басмасында басылып чыгарга тиеш.

Әлеге мәгълүмат шулай ук «Казанские ведомости» һәм «Шәһри Казан» газеталарында «Рәсми рәвештә бастыру» тамгасы белән бастырылырга мөмкин.

15. Фамилиясе, исеме, атасының исеме үзгәргән очракта, депутат Казан шәһәре Мэры исеменә яңа таныклык бирү турында язма гариза (сәбәбен күрсәтеп) җибәрә. Мондый очракта депутат гамәлгә яраксыз фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелгән депутат таныклыгын,раслаучы документлар кушып, яңа таныклык бирү турында язма гариза белән бергә җибәрә.

16. Депутат эшчәнлеген башкарган чираттагы чакырылыш Казан шәһәре Думасы вәкаләтләре чоры тәмамлангач, шулай ук депутат вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта депутатның таныклыгы гамәлгә яраксыз дип санала, ул Казан шәһәре Думасы аппаратына тапшырыла һәм әлеге Нигезләмәгә 5 номерлы кушымта нигезендә тиешле акт төзеп юкка чыгарыла, ә күкрәк билгесе депутатка истәлеккә саклау өчен кала.

17. Таныклыкны тапшыру көне теркәү журналында күрсәтелә. Бозылган күкрәк билгеләре һәм таныклыклары, шулай ук гамәлгә яраксыз фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелгән таныклыклар, әлеге Нигезләмәгә 5 номерлы кушымта нигезендә тиешле акт төзеп, юкка чыгарылырга тиеш.

18. Таныклык һәм күкрәк билгесен әзерләү буенча финанс чыгымнары Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле бюджетының Казан шәһәре думасы

эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелә торган акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**

Казан шәһәре Думасы депутаты
таныклыгы һәм күкрәк билгесе
турындагы Нигезләмәгә
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Думасы депутаты таныклыгы үрнәгенең тасвирламасы**

Казан шәһәре Думасы депутаты таныклыгы куе кызыл төстәге күн яисә ледерин тышлы, бөкләнгән килеш 100х65 мм һәм эчке тоташ бите буенча 200х65 мм зурлыктагы ике битле китаптан гыйбарәт.

Таныклык тышлыгының алгы ягында алтын төсендәге фольга белән түбәндәгеләр сурәтләнә:

беренче юл – «КАЗАН ШӘҺӘРЕ ДУМАСЫ» сүзләре;

уртада – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге гербының график сурәте;

аскы юл – «КАЗАНСКАЯ ГОРОДСКАЯ ДУМА» сүзләре.

Таныклыкның эчке сул һәм уң якларына (эчке тоташ биткә) 90х60 мм үлчәмдәге, уртасында гильошировкаланган челтәр һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге гербы булган персик төсендәге өстәмә бланк ябыштырыла.

Таныклыкның эчке сул ягында түбәндәге эчтәлекле текст языла:

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге**
Бердәм сайлау округы
**_____ НОМЕРЛЫ ТАНЫКЛЫК**
Татар телендә **Ф.И.А.**
Казан шәһәре Думасы депутаты
2025-2030 елларда гамәлдә

Таныклыкның эчке уң ягының сул өлешендә Казан шәһәре Думасы депутатының 30х40 мм зурлыктагы ялтырамый торган төсле фотосы урнаштырыла һәм түбәндәге эчтәлекле текст языла:

**Муниципальное образование город Казань**
Единый избирательный округ
**УДОСТОВЕРЕНИЕ №____**
**Ф.И.О.** на русском языке
Депутат Казанской городской Думы
Мэр города Казани ___________(Ф.И.О.)
Действительно на 2025-2030 годы

Казан шәһәре Мэрының имзасы һәм депутат фотосурәтенең аскы уң почмагы Казан шәһәре Думасы мөһере белән таныклана.

Депутат таныклыгының эчке ягындагы текст югары сыйфатлы принтер ярдәмендә кара буяу белән бастырыла.

Таныклыкка өстәмә битләр ялтыравыксыз 30 мкм ламинация белән каплана. Сул яктагы өстәмә битнең уң як кырыена алтын төсендәге фольга белән кайнар бастыру ысулы белән эшләнгән «толым» орнаменты төшерелә.

Казан шәһәре Думасы депутаты
таныклыгы һәм күкрәк билгесе
турындагы Нигезләмәгә
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Думасы депутаты таныклыгы үрнәге**

| | |
|---|---|
| | КАЗАН ШӘҺӘРЕ ДУМАСЫ<br><br>Казан гербы<br><br>КАЗАНСКАЯ ГОРОДСКАЯ ДУМА |

| | | |
|---|---|---|
| **Казан шәһәре**<br>**муниципаль берәмлеге**<br>Бердәм сайлау округы<br><br>**41 номерлы ТАНЫКЛЫК**<br><br>**ТУКАЕВА**<br>**ГҮЗӘЛ КӘРИМ КЫЗЫ**<br><br>Казан шәһәре Думасы депутаты | ФОТО<br>30 х 40 | **Муниципальное образование**<br>**город Казань**<br>Единый избирательный округ<br><br>**УДОСТОВЕРЕНИЕ №41**<br><br>**ТУКАЕВА**<br>**ГУЗЕЛЬ КАРИМОВНА**<br><br>Депутат Казанской городской Думы<br><br>Мэр города Казани ___________ (Ф.И.О.) |
| 2025-2030 елларда гамәлдә | Действительно на 2025-2030 годы | |

Казан шәһәре Думасы депутаты
таныклыгы һәм күкрәк билгесе
турындагы Нигезләмәгә
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Думасы депутатының күкрәк билгесе тасвирламасы**

«Казан шәһәре Думасы депутаты» күкрәк билгесе үзәгендә Зилант сурәте төшерелгән 33x17 мм зурлыктагы Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җилфердәп торган флагының стильләштерелгән рәсеменнән гыйбарәт.

Депутатның күкрәк билгесенең нигезе алтын белән 925 нче пробалы көмеш эретмәсеннән эшләнә, билгенең өслеге билгеләнгән пропорцияле Казан шәһәре флагы төсләрендәге эмаль белән каплана, билгенең кырыйлары алтыннан башкарыла. Билгенең өске өлешендә ак өслектә татар телендә алтын белән эшләнгән «Казан шәһәре Думасы депутаты» сүзләре урнаштырыла. Билгенең аскы өлешендә яшел өслектә рус телендә алтын белән эшләнгән «Депутат Казанской городской Думы» дигән сүзләр урнаштырыла.

Билгенең икенче ягында аның номеры күрсәтелә.

Күкрәк билгесе икеләтә цангалы «күбәләк» беркетүле, һәм (яисә) магнитлы беркетүле, һәм (яисә) винт-гайкалы итеп эшләнә.

Депутатның күкрәк билгесе өчен 54x57x34 мм зурлыгында куе кызыл төстәге флоктан футляр каралган.

Казан шәһәре Думасы депутаты
таныклыгы һәм күкрәк билгесе
турындагы Нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(форма)

**Казан шәһәре Думасы депутатлары таныклыкларын һәм күкрәк тамгаларын бирүне исәпкә алу журналы**

| № т/б | Депутатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Бирелгән таныклыкның, күкрәк билгесенең номеры | Таныклыкны, күкрәк билгесен бирү көне | Таныклыкны, күкрәк билгесен алу турында имза | Таныклыкны, күкрәк билгесен кире кайтару (алмаштыру) көне һәм сәбәпләре | Таныклыкны юкка чыгару турында актның номеры һәм төзелгән көне |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Казан шәһәре Думасы депутаты
таныклыгы һәм күкрәк билгесе
турындагы Нигезләмәгә
5 номерлы кушымта
(форма)

**Хезмәт таныклыкларын юкка чыгару турында АКТ**

20___ елның «____» __________ ______________номерлы

Рәисе ___________________________________________________________

______________________________________________ составындагы комиссия,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

комиссия әгъзалары:
____________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

Казан шәһәре Думасында таныклыклар юкка чыгару турында әлеге актны төзеде.

| № т/б | Таныклык номеры | Таныклык бирелгән затның вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Юкка чыгарылу сәбәбе |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Барлыгы юк ителергә тиеш таныклыклар ___________________.
(саны)

Комиссия рәисе:

___________________________________________________________________________

(имзасы, инициаллары, фамилиясе)

Комиссия әгъзалары:

___________________________________________________________________________

(имзасы, инициаллары, фамилиясе)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

20___ елның «___» __________

Мөһер урыны